**Карар № 87**

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Өҗем авыл җирлеге Советы**

Таш-Чишмә авылы 29 март 2024 ел

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Советының 2016 елның 16 декабрендәге 37 нче номерлы «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Өҗем авыл җирлегенең муниципаль милкенә хуҗасыз һәм җир милкен ачыклау, исәпкә алу һәм рәсмиләштерү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы прокурорының Өҗем авыл җирлеге Советының 2016 елның 16 декабрендәге 37 номерлы карары белән расланган (2020 елның 11 декабрендәге 11 номерлы карары редакциясендә) Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Өҗем авыл җирлегенең муниципаль милкенә хуҗасыз һәм җир милкен ачыклау, исәпкә алу һәм рәсмиләштерү тәртибе турындагы нигезләмәсенә 2024 елның 31 гыйнварындагы 02-08-02-2024/Прдп29-24 номерлы протесты нигезендә, Өҗем авыл җирлеге Советы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Өҗем авыл җирлегенең муниципаль милкенә хуҗасыз һәм җир милкен ачыклау, исәпкә алу һәм рәсмиләштерү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакындагы» 2016 елның 16 декабрендәге 37 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның фабуласын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 225 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 50 статьялары, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» гы 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон, Росреестрның «Хуҗасыз күчемсез милекне исәпкә алу тәртибен билгеләү турында» гы 2023 елның 15 мартындагы П/0086 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге уставы нигезендә, Өҗем авыл җирлеге Советы карар итте:”;

1.2. Нигезләмәләрнең 1 бүлегенең 1.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

“1.1. Өҗем авыл җирлегенең муниципаль милкенә хуҗасыз һәм җир милкен ачыклау, исәпкә алу һәм рәсмиләштерү тәртибе турындагы нигезләмәсе (алга таба - Нигезләмә) Россия Федерациясе Гражданнар кодексы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар белән, "Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында" 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон, Росреестрның «Хуҗасыз күчемсез милекне исәпкә алу тәртибен билгеләү турында» гы 2023 елның 15 мартындагы П/0086 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге уставы нигезендә эшләнгән.”;

1.3. Нигезләмәдә 5 нче кушымтаның 6 пунктындагы «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1998 елның 18 февралендәге 219 номерлы карары белән расланган

«Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм аның белән алыш-бирешләрнең Бердәм дәүләт реестрын алып бару тәртибе» сүзләрен «Росреестрның 07.12.2023 № П/0514 боерыгы белән расланган «Күчемсез мөлкәткә хокуклар һәм аның белән алыш-бирешләр реестрын алып бару кагыйдәләре» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (www.atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Өҗем авыл җирлеге башлыгы: Вәлиев А.Т.